СОВЕТ МАЛОКИРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.З.Закирова, д.47, с. Малые Кирмени,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422172

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ КИРМӘНАВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
З.Закиров ур., 47 нче йорт, Кече Кирмән авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422172

тел.(факс): (85563) 2-96-17; e-mail: MKir.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение Карар

№ 7-7 «03» март 2016 ел

2016 елның 28 февралендә референдумда
кабул ителгән карарны теркәү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, 2015 елның 1 мартында референдум нәтиҗәләре нигезендә: «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2016 елда 200 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:
- торак пункт чикләрендә халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, су чыгару, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:
- су үткәрү һәм су үткәргеч торба салу;
- су башнялары урнаштыру
- тирәнлек насосын урнаштыру
- тимер-бетон терәкләр урнаштыру белән электр линиясе үткәрү
- су башняларында су дәрәҗәсен көйләү өчен автоматик җайланма урнаштыру-100,0 мең сум
-- «Әйе» «Юк»

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2016 елның 29 февралендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Кече Кирмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында» 32 номерлы карарын теркәргә.
2. Гражданнарның үзара салым акчаларын куллану юнәлешләрен һәм күләмнәрен кушымта буенча билгеләргә.
3. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Мамадыш муниципаль районы
Кече Кирмән авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /Г.М.Аскаров /

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге Советының 3 март, 2016 ел, № 7-7 карарына
КУШЫМТА

# Гражданнарның үзара салым акчаларын куллану юнәлешләре һәм күләмнәре

| N т/п | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең атамасы | Шул исәптән планлаштырылган чаралар | чараларны гамәлгә ашыруга акча күләме, мең сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | торак пункт чикләрендә халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, су чыгару, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру | Кече Кирмән торак пунктында су үткәрү һәм су үткәргеч торба салу- 500 метр;<br>су башнялары урнаштыру- 1 шт.;<br>тирәнлек насосын урнаштыру-1 шт.;<br>тимер-бетон терәкләр урнаштыру белән электр линиясе үткәрү-200 метр;<br>су башняларында су дәрәҗәсен көйләү өчен автоматик җайланма урнаштыру- 1 шт.; | 100,0 |
| Барлыгы | | | 100,0 |